ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2021 Олы Кайбыч ав. 450

2022 елга «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмалары һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 10 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2022 елга:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмалары һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын кушымтада каралганча;

туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын

гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмәләр коэффициентын 0,5 күләмендә раcларга.

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына»:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эшне яңадан карауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында, «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э. Х. Заһидуллина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021е. «03» 11 450 номерлы
карарына кушымта

**2022 елга «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмалары һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучына елына сум) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укытуның беренче елы | укытуның икенче елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый фәнни | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |